**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы №77 «24»ноябрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге 2017 елның 28 августындагы 60 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең юбилеена бәйле рәвештә Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә бирелә торган өстәмә гарантия турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге 2017 елның 28 августындагы 60 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең юбилеена бәйле рәвештә Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә бирелә торган өстәмә гарантия турында»гы карарына «Юбилейга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә бирелә торган өстәмә гарантия турында» сүзләрен тиешле килештә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәренә бирелә торган бер мәртәбә бирелә торган өстәмә түләү турында» сүзләренә алмаштырып ,түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2. кушымтада:

2.1. 1.4 пункт түбәндәге эчтәлекле икенче - унберенче абзацлар белән:

"Матди ярдәм рәвешендә өстәмә социаль һәм башка гарантияләр күләменә:

- вазыйфаи оклад;
- класс чины өчен вазыйфаи окладка өстәмә;
- Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләменең 1/12 өлеше;

тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына өстәмә;

- вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү;
- муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнгә кадәр кимендә алты ай кала билгеләнгән күләмдә айлык өстәмә;
- дәүләт сере булып торган мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә өстәмә түләү;
- нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә компенсация түләүләре;
- профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә өстәмә түләү.».

2. 3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова